*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№7 (54)

Апрель, 2022 нче ел

Бу санда

*Тукай - татар милләте символы* 2

*Белем - бәхет ачкычы* 2

*1 апрель – Халыкара кошлар көне* 3

*Табигатьне саклау - изге бурычыбыз* 3

*Милләтем киләчәге* 4

*Күңел чыңы. Илһам канатларында* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### «Тату сыйныф серләре» ата-аналар комитетлары республика конкурсы җиңүчеләре




8 апрельдә Чаллы шәһәренең 1 нче балалар һәм яшьләр иҗат сарае базасында «Дуслык сыйныфы серләре» конкурсының ярымфиналы узды. Гимназиянең 6 нчы б сыйныфы ата-аналар комитеты Мөслим муниципаль районын лаеклы тәкъдим итте һәм ярымфинал җиңүчеләренең берсе булды!!!

20 нче апрельдә 6 нчы б сыйныф укучылары Кукмарада узган финал ярышында катнашып, 13 команда арасында икенче урынга лаек булдылар. Сыйныф җитәкчесе Чулпан Хайруллина ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мактаулы остаз» мактау билгесе белән бүләкләнде. Икенче урын - тырыш хезмәт, бердәмлек нәтиҗәсе. Җиңүчеләргә Анапага Кара диңгез ярларына юлламалар тапшырылды.

Балаларны, әти-әниләрне, Чулпан Алмаз кызын һәм барлык катнашучыларны югары нәтиҗәләр белән котлыйбыз! Горурланабыз!

### Сферум уку профиле лидерлары



Казан шәһәрендә, цифрлы сервис-уку профилен кулланып, белем бирү процессын нәтиҗәле оештырган өчен гомуми белем бирү учреждениеләре һәм ТР педагоглары арасында җиңүчеләрне хөрмәтләделәр. Мөслим гимназиясе коллективы - лидерлар арасында. Гимназия ноутбук белән бүләкләнде. Гимназия директоры Мирзаянов А.Ф., Шәрифуллин А.Р., Галиева И.Т., Мөхәммәтҗанова Г.И., Мөхәммәтдинова Р.Р., Кадыйрова А.Р.га Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәхмәт хаты, Сферум цифрлы сервисының дипломнары һәм кыйммәтле бүләкләре тапшырылды. Җиңүчеләрне котлыйбыз!

### «Балалар илне рәсемгә төшерәләр»




3 нче а сыйныф укучылары, сыйныф җитәкчесе Гомәрова Алсу Раиил кызы җитәкчелегендә, «Балалар илне рәсемгә төшерәләр» республика рәсем конкурсында катнаштылар.

«Татарстан» ДТРК ВГТРК ФДУП филиалы («Россия - 1», «Россия - 24» телеканаллары) корресподентлары репортаж төшерделәр.

Республика күләмендә жюри конкурска 8 июньгә кадәр йомгак ясый. Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү 12 июньдә Россия көнен бәйрәм итүгә багышланган тантана барышында узачак.

## ТУКАЙ - ТАТАР МИЛЛӘТЕ СИМВОЛЫ



*Габдулла Тукай (1886-1913)*

***26 апрель - бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көне. Шул уңайдан кайбер Тукайның шигырьләрен тәкъдим итәбез.***

### Киңәш («Якын дустым…)

Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул:
Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул.
Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.
Ачып яшьрен хәзинәңне йөрәктән,
Сөйләшмә бер дә артык сүз кирәктән:
Кешеләр үзләрен анчак сөярләр,
Бәхетсезләрнең өстеннән көләрләр.
Алар ерткыч, алардан читтә бул син,
Алар барда бүрең бер якта торсын.
Серең белгәч кызартырлар йөзеңне,
«Җүләр бу!» - дип ачырмаслар күзеңне.
Кача күр, кош кеби, мактауларыннан,
Хәбәрдар бул ки шунда ау барыннан.
Әгәр басса сине бер-бер заманны
Еламый йомшамас хәсрәт вә кайгы, —
Утыр аулакка, кайда һич кеше юк,
Сабыйдай, тәмле-тәмле күз яше түк.
Килеп керсә берәү нәкъ шул чагында,
Сиңа мин бер киңәш әйтим тагын да:



*Тукай китаплары*

***"Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул"***

*Габдулла Тукай*




Диген син: «Күзләрем никтер авырта, Өзелми яшь ага кич һәм дә иртә!»

### Чын вә ялган

Әүвәле дөньяда җир юк, су гына булган, диләр;
Анда йөзгәннәр имеш тик Чын белән Ялган, диләр.
Бу ике дошманга Тәңредән бирелгән бер көймә,
Бәс, утырганнар көймәгә берсе каршы берсенә.
Күп тә йөрми, Чын белән Ялган чыгарганнар сугыш, –
Булмаса дустлык, җитә бит сугышырга бер юк эш.
Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан ди дә,
Чын батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә!

## БЕЛЕМ - БӘХЕТ АЧКЫЧЫ

### Имтиханнар якынлаша



Имтиханнар тапшырырга санаулы көннәр генә калып бара. Укылып бетмәгән материалны тизрәк үзләштерергә, алган белемне камилләштерергә кирәк. Алдан әзерләнгән эш хәерле була. Шуңа күрә ел буе тупланган белемеңә таянып, барысын да башкарып чыга алуыңа өметләнергә кирәк. Әлбәттә, имтиханнар алдыннан дулкынлану нормаль күренеш. Барлык сәламәт кешеләр дә мөһим вакыйгалар алдыннан борчыла.

Имтиханда программа кысаларыннан тыш сораулар булмаячак. Әгәр дә син фәнне өйрәнгән булсаң, имтиханны ничек тә булса тапшыра аласың. Әлбәттә, ман-дражны бетерүнең иң яхшы чарасы – үз-үзеңә ышанычның уята торган яхшы әзерлек.

### Проект - иҗади эшчәнлек, эзләнү-тикшеренү эше

Проектларны укучылар уку елы башында ук сайлап ала һәм ел дәвамында үзләре өстенлек биргән юнәлеш буенча эшли. Төп таләп – проект продуктив булырга, ягъни теория белән практик өлеш тәңгәл килергә тиеш.

Уку елы ахырында укучыларыбыз үз проектларын якларга тиеш. Һәр укучы үзе сайлаган проектны тәкъдим итә.













# 1 АПРЕЛЬ – ХАЛЫКАРА КОШЛАР КӨНЕ

## "Язны сәламли кошлар"

Кошлар көненең ничек барлыкка килү тарихы да бик кызыклы. Иң беренчеләрдән булып аны АКШта 1894 елда билгеләп үткәннәр. Тиздән бәйрәм барлык штатларда үткәрелә башлый, аннары Европага килеп җитә.

1906 елдан башлап дөньякүләм Халыкара кошлар көне үткәрелә башлый, ә Россия моңа 1927 елда кушыла. Шулай итеп, 1927 елның 1 апреленнән безнең илдә дә кошлар көнен үткәрү традициягә кергән.

Әлеге көнне кешелек дөньясының табигать белән берләшүе дисәк тә, ялгыш булмас. Бәйрәм генә түгел, ә канатлы дусларыбызга ярдәм итү көне ул. Яз килүен хәбәр итүче күчмә кошлар – март азагы, апрель башында туган якларына әйләнеп кайталар. Бу көнне олылар да, балалар да кошларга мөмкин кадәр ярдәм итәләр: су кошларының яшәү урыннарын төзекләндерәләр, сыерчык оялары эләләр, аларга азык салалар.

## Канатлы дусларыбызны ничек каршылыйбыз?



Озын кышны чыккан һәм бик нык йончыган, хәлсезләнгән кошлар аеруча күп үлә. Бу чорда аларны тукландыру турында кайгыртсагыз, күчмә кошлар өчен оялар әзерләп куйсагыз бик зур һәм игелекле эш эшләрсез.

Гадәти сыерчык һәм песнәк ояларын чебенчеләр, чыпчыклар, керәшә, үткойрыклар да бик ярата. Бу ояларны көздән элеп калдыру яхшы. Әгәр көздән өлгермәгән булсагыз, март, хәтта апрель айларында да соң түгел. Оялар нык һәм тишек ярыксыз булырга тиеш. Фанерадан кала, аларны теләсә нинди тактадан ясарга мөмкин. Тактаны тышкы яктан гына ышкылыйлар, эчке як, кошларга оядан чыгарга уңайлы булсын өчен, кытыршы килеш калдырыла.

Күп кенә кошлар багана ояны яраталар. Мондый ояны агач тумранының эчен уеп ясыйлар. Башта тумранны урталай ярып, эчен өтергә белән чокыйлар, аннан ике кисәкне бергә кушып, тимерчыбык белән борып куялар. Ярыкны сылыйлар.

Кошлар ачык төсләргә буялган яки яңа гына ышкылап эшләнгән ояны яратмыйлар. Буялган очракта да ояны куе марганцовка эремәсе белән буяу яхшы. Ояларны бераз алга авыш итеп, биек җиргә эләләр.

***Минһаҗева Камилә,***
***10 нчы сыйныф укучысы***

# ТАБИГАТЬНЕ САКЛАУ - БЕЗНЕҢ ИЗГЕ БУРЫЧЫБЫЗ

## Экояз - 2023



Озакка сузылган йокысыннан уянган табигать безнең дә «күзләрне ачарга» мәҗбүр итә. Кар юрганы астыннан баш калкыткан чүп-чар да күзгә чалына, көздән чабылмый, чистартылмый калган үлән-курайлар да пәйда була. Әйләнә-тирәбез – чистарту-җыештыру, җир-анабыз кайгырту сорый.

ТР Министрлар Кабинеты боерыгын үтәү йөзеннән район Башкарма комитеты быел да 1 нче апрельдән 31 нче майга кадәр район территориясен санитар чистарту һәм төзекләндерү буенча санитар-экологик ике-айлык үткәрү турында карар кабул итте.

Гимназия укучылары да бу акциядән читтә калмый. Алар әти-әниләренә, әби-бабайларына капка төпләрен, ишегалды, бакчаларын чүп-чардан тазартырга булышалар. Гимназия территориясе дә өмәдән соң, балкып калды.


## Экологик конференция җиңүчесе




Олимпиада чаралары кысаларында ел саен Идел буе мәктәп укучыларының экологик конференциясе үткәрелә. Мөслим гимназиясенең 9 нчы а сыйныфы укучысы Ханнанова Адилә үзенең фәнни-тикшеренү эшен тәкъдим итте һәм яклады. Адилә тикшеренү эшен тирәнтен белгәне һәм докладының югары бәяләнүе өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дипломына лаек булды.

## Экологик дәресләр гөрләп үтә



# МИЛЛӘТЕМ КИЛӘЧӘГЕ

## «Әдәби карта» җиңүчесе



12 нче апрель көнне Татарстан Язучылар берлеге һәм «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп» журналлары оештырган «Әдәби карта» конкурсының җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы булды. Әлеге бәйгедә беренче урынны, «Бөкәч» хикәясе өчен, Мөслим гимназиясенең башлангыч сыйныф укытучысы Хәсәнова Миләүшә Кәшбетдин кызы яулады.

Миләүшә Кәшбетдиновна, иҗат чишмәгез саекмасын, каләмегез гел тибрәлеп торсын!

Котлыйбыз, Миләүшә Кәшбетдиновна!

## Татар егете – 2023




Чаллы шәһәрендә төбәкара «Татар егете - 2023» конкурсының финал этабы узды. Әлеге конкурста гимназиябызның 10 нчы сыйныф укучысы Мөхсинов Ислам «Көчле егет» номинациясендә җиңү яулады.

Аяз Гыйләҗев исемендәге «Чаллы татар дәүләт драма театры» барлык финалистларны узләренең спектакльләренә чакырды.

Әфәрин, Ислам!

## Газетабыз уңышлары



Казан шәһәрендә үткән Туфан Миңнуллин исемендәге фәнни-гамәли конференциядә 10 нчы сыйныф укучысы Минһаҗева Камилә катнашып призер булды. Камилә гимназия газетасы «Тылсым+» ны тәкъдим итте. Шулай ук Казан шәһәрендә үткәрелгән IV региональ (Идел буе) иҗат конкурсында Минһаҗева Камилә «Иң яхшы информацион мәгълүмат чарасы» номинациясендә беренче урынга, 11 нче сыйныф укучы-сы Солтанова Алия «Иң яхшы эссе» номинациясендә икенче урынга лаек булдылар. Җитәкчеләре Солтанова Г.М., Кадирова А.Р.

# КҮҢЕЛ ЧЫҢЫ. ИЛҺАМ КАНАТЛАРЫНДА

## Зирәккә дә тәрбия кирәк

*(хикәя)*

Миңа ике яшьләр булганда, Энҗе апам песи баласы алып кайтты. Хәер, аның безнең йортта ничек пәйда булганын мин хәтерләмим. Чөнки бик кечкенә булганмын. Мин үсә төштем, минем белән песи баласы да үсте. Аның исеме - Зирәк. Ул бик матур: аклы-җирәнле төстә, ә күзләре ямь-яшел. Зирәк бар нәрсәне аңлаган кебек, шундый акыллы итеп карый. Ләкин аның бик начар гадәте бар: аш өстәлендә нәрсә бар, шуны менеп урлый. Песинең бу гадәтен эти ошатмады. Бер көнне, түземлеге бетеп:

- Зирәк бүгеннән башлап, тышта яшәр! Абзарда җылы, кирәк булса, сәндерәгә менеп йоклар, – диде.

Безнең гаиләдә әтинең сүзе – закон. Беркем дә каршы сүз әйтмәде. Зирәк абзарда яши башлады. Аны һәркөнне җылы аш, сөт белән сыйлыйбыз. Ә пескәй әтинең күңелен йомшартырга теләгәндәй, әле тычкан, әле кумак эләктерә. Тоткан тычканын әтинең аяк астына алып килеп ташлый, үзенчә мактанган була. Әти аны: «Булдыргансың! Акыллы шул син!» - дип мактап куя.

Энҗе апам институтка укырга керде. Ул ялларга кайтып, кире укырга киткән чакта, Зирәк һәрвакыт апамны озатып кала торган булды. Мин Зирәкне бик яратам. Песием әчтән генә ниләр уйлый микән? Аның яшел, акыллы күзләрендә ниләр яшеренгән? Миңа шул хакта минем бик тә беләсем килә! Шул максат белән песиләр хакында интернет челтәреннән бик күп мәгълүматлар укыйм. Белгәннәремне әни белән уртаклашам:

- Әни! Әнием! Беләсеңме, песиләр хуҗаларын - эти-әниләре, туганнары итеп кабул итә икән! Ә этләр – дуслары итеп. Чөнки, борын-борын заманда песиләр үз гаиләләре белән генә, ә этләр көтүләр булып яшәгәннәр.

- Каян белдең бу хакта? - ди әни, гаҗәпләнеп.



- Интернеттан укыдым!

Әни бераз миңа курыккан кыяфәттә карап торды да:

- Ничек килеп чыга, без үзебезнең баланы тышка куып чыгардыкмени?!

- Шулай килеп чыга, - дидем мин, авыр сулап.

- Юк! Болай ярамый! Мин Зирәкне өйгә алып керәм!- диде әни, катгый карарга килеп.

Әнием Зирәкне өйгә алып керде. Песинең ап-ак йоннары каралган, колаклары кителгән, ә борынына томау төшкән.

- И бичара, яше дә шактый бит инде, - дип сөйләнде әни. Зирәкне җылы мунчага алып барып, табакка утыртып юындырдык. Ни гаҗәп, песиебез тыпырчынмады, җылы суда изрәп, мырлый гына бирде. Аны чүпрәккә төреп, корыттык та, өйгә урын әзерләп яткырдык. Песиебез рәхәтләнеп йоклап китте.

Әни Зирәккә ике савыт әзерләде: берсе су, икенчесе ризык өчен.

- Аның савытларын чистартып тору – сезнең өстә! - диде әни, энем белән миңа. – Тагын бер нәрсәне исегездән чыгармагыз: «урлаган – бер гаепле, урлаткан – ике» дигәннәр борынгылар. Аш өстәлен җыеп йөрсәк, песи дә урлашырга менмәс, менсә дә коры төшәр. Зирәкне тәрбияләү – безнең бурыч. Ул бит безнең гаилә әгъзасы! - дип өстәде, миңа елмаеп әнием.

Ләкин бер мәсьәлә әле чишелмәгән иде.

- Ә эти ни әйтер? - диде энем, күзләрен зур ачып.

- Борчылмагыз! Әтиегез белән мин үзем сөйләшермен.

Шулай итеп, Зирәк өйдә яши башлады. Песи күзгә күренеп тазарды, матурланды. Аның булуы өйтеп бетергесез, өйгә ямь өстәде. Хәрберебез Зирәкнең кыланмышларына сокланып та гаҗәпләнеп тә карыйбыз, аның белән сөйләшә башлады. Хәтта эти дә: «Нәрсә, Зирәк, бүген тәртипле булдыңмы?» - дип, аны сыйпап та ала башлады. Әлбәттә инде, без аңа Зирәкнең, кайчагында арт аякларына басып, буш өстәл өстен күзәткәләгәнен әйтмибез!

***Зәкиева Әминә,***
***6 нчы в сыйныфы укучысы***

**ТЫЛСЫМ+**
**Март, 2023 нче ел**
**№7 (54)**
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Минһаҗева Камилә
**Корректорлар:** Минһаҗева Диләрә
**Корреспондентлар:** Солтанова Алия, Айгельдина Зарина
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3) **Тираж:** 100